РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» февраль 2023 ел г. Альметьевск № 290

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«Каникул вакытында балаларның
ялын оештыру буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын
раслау турында» 2021 елның
22 декабрендәге 1888 номерлы
карарына үзгәреш
кертү турында

Административ регламентны актуальләштерү максатларында, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарының 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 декабрендәге 1888 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

3 бүлекнең 3.3 пунктының 3.3.2.1 пунктчасындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче тарафыннан соратуның электрон формасы кырларын тутыру процессында автомат рәвештә, орган (оешмалар) билгеле торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формасы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны мөрәҗәгатьнең электрон рәвешендә турыдан-туры мәгълүмати хәбәр итү юлы белән бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Зак. № 305-2000

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма а комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов